ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

25.12.2020 Олы Кайбыч ав. № 558

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы территориясендә муниципаль җир контролен гамәлгә ашырганда тикшерүләр уздыру административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«2021 елга юридик затларга һәм индивидуаль эшмәкәрләргә планлы тикшерүләр уздыруның, 2021 елга тикшерүләр уздыруның һәм дәүләт контроле (күзәтчелеге) органнары һәм муниципаль контроль органнары тарафыннан ел саен юридик затларга һәм индивидуаль эшмәкәрләргә планлы тикшерүләр уздыруның еллык планнарын әзерләү кагыйдәләренең 7 пунктына үзгәрешләр кертү үзенчәлекләре турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 30 ноябрендәге 1969 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы территориясендә муниципаль җир контролен гамәлгә ашырганда тикшерүләр уздыру административ регламентын раслау турында» 2019 елның 29 мартындагы 151 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы территориясендә муниципаль җир контролен гамәлгә ашырганда тикшерүләр уздыру административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

VI бүлекне түбәндәгн редакциядә бәян итәргә:

**«VI. 2021 елда юридик затларга һәм индивидуаль эшмәкәрләргә карата муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда планлы тикшерүләр оештыру һәм уздыру үзенчәлекләре**

6. 2021 елда «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында» Федераль законның 4 статьясы нигезендә кече эшмәкәрлек субъектларына караган, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының бердәм реестрына кертелгән юридик затларга һәм индивидуаль эшмәкәрләргә (алга таба - кече эшмәкәрлек субъектлары) карата планлы тикшерүләр үткәрелми.

Чикләүләр түбәндәгеләргә кагылмый:

а) эшчәнлекләре һәм (яки) кулланыла торган җитештерү объектлары югары һәм аеруча югары хәвеф-хәтәр категорияләренә кертелгән йә хәвеф-хәтәрнең 1, 2 классларына (категорияләренә), куркыныч җитештерү объектларының I, II һәм III куркыныч классына, гидротехник корылмаларның I, II һәм III классларына кертелгән, шулай ук аларга карата даими дәүләт контроле (күзәтүн) режимы билгеләнгән затларны планлы тикшерүләр;

б) исемлеге «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм индивидуаль эшмәкәрләрнең хокукларын яклау турында» Федераль законның 9 статьясындагы 9 өлеше нигезендә Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә торган эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашыручы затларга планлы тикшерүләр;

в) муниципаль контроль органында кече эшмәкәрлек субъектларына элек законлы көченә кергән «Эшчәнлекнең аерым төрләрен лицензияләү турында» Федераль закон нигезендә бирелгән лицензиянең гамәлдә булуын туктатып тору яисә эшчәнлекне дисквалификацияләү, яисә административ туктатып тору рәвешендә административ җәза бирү турында Россия Федерациясе кодексы нигезендә билгеләнгән тупас хокук бозу кылган өчен административ җәза билгеләү турында карар чыгарылган булса, кече эшмәкәрлек субъектларын планлы тикшерүләр «Эшчәнлекнең аерым төрләрен лицензияләү турында» Федераль закон нигезендә бирелгән лицензиянең гамәлдә булуын туктатып тору турында һәм (яисә) лицензияне юкка чыгару хакында карар кабул ителгән, һәм нәтиҗәләре буенча шундый карар чыгарылган йә шундый карар кабул ителгән тикшерүне уздыру тәмамланган датадан алып, 3 елдан да азрак вакыт үткән. Шул ук вакытта ел саен «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм индивидуаль эшмәкәрләрнең хокукларын яклау турында» Федераль законның 9 статьясындагы 4 өлешендә каралган белешмәләрдән тыш, аның нәтиҗәләре буенча мондый карар чыгарылган йә шундый карар кабул ителгән булса, күрсәтелгән карар турында, аларның законлы көченә керү датасы һәм тикшерү уздыруны төгәлләү датасы турында мәгълүмат китерелә;

г) лицензия контролен гамәлгә ашырганда уздырыла торган планлы тикшерүләр;

д) түбәндәге кысаларда уздырыла торган кече эшмәкәрлек субъектларын планлы тикшерүләр:

радиация куркынычсызлыгын тәэмин итү өлкәсендә федераль дәүләт күзәтчелеге;

дәүләт серен яклауны тәэмин итүгә федераль дәүләт контроле;

«Аудиторлык эшчәнлеге турында» Федераль законда билгеләнгән аудиторлык оешмалары эшенең сыйфатын тышкы контрольдә тоту;

атом энергиясен файдалану өлкәсендә федераль дәүләт күзәтчелеге.

6.1. Әлеге статья таләпләрен бозып планлы тикшерү үткәрү муниципаль контроль турында законнар таләпләрен тупас бозу булып тора һәм «Муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм индивидуаль эшмәкәрләрнең хокукларын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ

номерлы Федераль законның 20 статьясындагы 1 өлеше нигезендә тикшерү нәтиҗәләренең гамәлгә яраксызлыгына китерә.».

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http:/ kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында» бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Кайбыч муниципаль районы
Башкарма комитеты Җитәкчесе
Вазыйфаларын
башкаручы Э.Х.Заһидуллина